АГЕНТСТВО ИНВЕСТИЦИОННОГО РАЗВИТИЯ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ИНВЕСТИЦИОН ҮСЕШ АГЕНТЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

**«28» июня 2019** **№ 28**

Казан

Татарстан Республикасының инвестицион үсеш агентлыгында биләүләре коррупция куркынычы белән бәйле булган, дәүләт граждан хезмәткәрләре үзләренең керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат бирергә тиешле дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары Исемлеген раслау турында

«Коррупциягә каршы тору турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законны, Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфасын биләгәндә Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре үз керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат, шулай ук үз хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат бирергә тиешле вазыйфалары исемлеген раслау турында» 2009 елның 30 декабрендәге УП-701 номерлы Указы, «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын биләүне дәгъвалаучы гражданнар тарафыннан керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү турында, шулай ук Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре тарафыннан керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү хакында» 2009 елның 30 декабрендәге

УП-702 номерлы Татарстан Республикасы Президенты Указын башкарып,

БОЕРУ:

1. Татарстан Республикасының инвестицион үсеш агентлыгында биләүләре коррупция куркынычы белән бәйле булган, дәүләт граждан хезмәткәрләре үз керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат бирергә тиешле дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары Исемлеген расларга (алга таба - Исемлек).

2. Татарстан Республикасының инвестицион үсеш агентлыгының юридик бүлегенә:

2.1. «Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 12 статьясында, алар эштән киткәндә Исемлеккә кертелгән вазыйфаларны биләгән дәүләт граждан хезмәткәрләренә каралган чикләүләрне, бурычларны һәм җаваплылыкны аңлатырга.

2.2. Әлеге боерыкны Исемлеккә кертелгән дәүләт граждан хезмәткәрләренә җиткерергә.

3. Татарстан Республикасының инвестицион үсеш агентлыгының «Татарстан Республикасының инвестицион үсеш агентлыгында биләүләре коррупция куркынычы белән бәйле булган, дәүләт граждан хезмәткәрләре үз керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат бирергә тиеш булган дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары Исемлеген раслау турында» 26.12.2017 елдан № 40 боерыгы үз көчен югалткан дип санарга.

4. Әлеге боерыкның үтәлешен контрольдә тотуны үзем артыннан калдырам.

Җитәкче Т.И. Миңнуллина

Татарстан Республикасының
инвестицион үсеш агентлыгының
2019 елның 29.06 №28
боерыгы белән расланган

**Татарстан Республикасының инвестицион үсеш агентлыгында биләүләре коррупция куркынычы белән бәйле булган, дәүләт граждан хезмәткәрләре үзләренең керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат бирергә тиешле дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары Исемлеге**

| №№ пп | Вазыйфасы атамасы | Вазыйфалар саны |
|---|---|---|
| | **Җитәкчелек** | |
| 1 | Җитәкченең беренче урынбасары | 1 |
| 2 | Җитәкче урынбасары | 1 |
| | **Инвестицион проектларны экспертиза бүлеге** | |
| 1 | Бүлек башлыгы | 1 |
| 2 | Әйдәп баручы киңәшче | 2 |
| | **Инвестицион проектларны алып бару һәм аларга ярдәм итү бүлеге** | |
| 1 | Бүлек башлыгы | 1 |
| 2 | Әйдәп баручы киңәшче | 2 |
| 3 | Әйдәп баручы консультант | 1 |
| | **Мәгълүмати-аналитика бүлеге** | |
| 1 | Бүлек башлыгы | 1 |
| | **Дәүләт-хосусый партнерлыкны үстерү бүлеге** | |
| 1 | Бүлек башлыгы | 1 |
| | **Юридик бүлек** | |
| 1 | Бүлек башлыгы | 1 |
| | **Финанс исәбе һәм дәүләт сатып алулары бүлеге** | |
| 1 | Бүлек башлыгы | 1 |
| 2 | Әйдәп баручы белгеч | 2 |
| | **Массакүләм мәгълүмат чаралары белән эшләү бүлеге** | |
| 1 | Бүлек мөдире | 1 |
| | **Матди-техник тәэмин итү бүлеге** | |
| 1 | Бүлек мөдире | 1 |
| | Барлык: | 17 |